**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Югары Стәрле авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Югары Стәрле авылы № 89-56 «2»апрель 2018 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Югары Стәрле авыл җирлеге Советының 2012 елның 21 апрелендәге 39номерлы карары белән расланган Югары Стәрле авыл җирлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында (30.01.2015 №125, 30.09.2015 №5-3, 04.03.2016 №27-15 карарлар редакциясендә)

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 30 октябрендәге 299-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 29 декабрендәге 455-ФЗ номерлы Федераль законнарны үтәү йөзеннән

Югары Стәрле авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1.

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Югары Стәрле авыл җирлеге Советының 2012 елның 21 апрелендәге 39номерлы карары белән расланган Югары Стәрле авыл җирлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәгә (30.01.2015 №125, 30.09.2015 №5-3, 04.03.2016 №27-15 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«1.4. Халык тыңлауларына мәҗбүри тәртиптә чыгарыла:

1) җирлек уставы проекты, шулай ук гамәлдәге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый акт проекты, Уставка Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, конституция (Устава) яисә Татарстан Республикасы законнары нигезләмәләрен төгәл кабатлау рәвешендә үзгәрешләр кертү очракларыннан тыш, гамәлдәге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый акт проекты;

2) җирлек бюджеты проекты һәм аның үтәлеше турында хисап;

3) җирлекнең социаль-икътисадый үсеш стратегиясе проекты;

«1.4. Халык тыңлауларына мәҗбүри тәртиптә чыгарыла:

1) җирлек уставы проекты, шулай ук гамәлдәге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый акт проекты, Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Конституция яисә Татарстан Республикасы законнары нигезләмәләрен төгәл кабатлау рәвешендә үзгәрешләр кертү очракларыннан тыш, гамәлдәге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый акт проекты;

2) җирлек бюджеты проекты һәм аның үтәлеше турында хисап;

3) җирлекнең социаль-икътисадый үсеш стратегиясе проекты;

4) «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы 13 статьясы нигезендә җирлекне үзгәртеп кору өчен тавыш бирү юлы белән яисә граждааннар җыеннарында белдерелгән җирлек халкының ризалыгын алу таләп ителгән очраклардан тыш.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Югары Стәрле авыл җирлегенең законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Рәис Л.С. Сабирҗанова